| СОВЕТ<br>БОЛЬШЕАЧАСЫРСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| --- | --- |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2024 елның 4 апреле Олы Ачасыр авылы № 175

Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2021 елның 15 июлендәге 49 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында (Советның 2022 елның 2 сентябрендәге 96 номерлы, 2023 елның 23 августындагы 147 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зеленодольск муниципаль районының Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә, Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2021 елның 15 июлендәге 49 номерлы карары белән расланган (Советның 2022 елның 2 сентябрендәге 96 номерлы, 2023 елның 23 августындагы 147 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Җир кишәрлекләрен тоту» 4 нче бүлекнең 1 нче пунктының унөченче абзацында «, тимер юллар» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. «Тышкы яктырту объектларын (чараларын) тоту» 4 нче бүлекнең 7 нче пунктында, «, иҗтимагый (тимер юл) транспортының контакт челтәренең терәкләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. «Тышкы яктырту объектларын (чараларын) тоту» 4 нче бүлекнең 8 нче пунктының беренче абзацында «, җәмәгать (тимер юл) транспортының контакт

челтәре терәге күрсәтелгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.4. «Тышкы яктырту объектларын (чараларын) тоту» 4 нче бүлекнең 9 нчы пунктында «җәмәгать (тимер юл) транспортының контакт челтәре терәкләре» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

Олы Ачасыр авыл жирлеге
башлыгы, Совет рәисе




И.М. Саттаров